ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2024 Олы Кайбыч ав. № 460

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

Халыкның җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларының тормыш эшчәнлеге, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен уңай шартларга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны 2024 елның 17 декабрендә 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк бинасының актлар залында уздырырга.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты материаллары (текст һәм график өлеш) белән эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 нче йорт, 2 нче кат, 209 нчы кабинет адресы буенча танышырга мөмкин.

3.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр җыю урыны итеп Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеген билгеләргә.

4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

-«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүмат урнаштырырга;

- әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Ю.В. Гайнуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров